Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы
Иске Кыязлы авыл җирлеге составына керүче Кзыл Тау торак пунктында үткәрелгән халык җыены нәтиҗәләре турында
КАРАР

14 нче ноябрь 2019 нчы ел №1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми ринциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 маддәсе, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы “Иске Кыязлы авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 24 маддәсе, Иске Кыязлы авыл җирлеге Советының 2019 елның 5ноябрендә кабул ителгән 89 нчы номерлы “Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кыязлы авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау турындагы” Карары нигезендә Иске Кыязлы авыл җирлеге составына керүче Кзыл Тау торак пунктында 2019 нчы елның 29 октябрендә һәм 12 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән халык җыеннары нәтиҗәләрен кабул итәргә: “2021 елда Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кыязлы авыл җирлеге составына керүче Кзыл Тау авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, I төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм көндезге бүлектә белем алучы студентлардан тыш, 400 сум күләмендә үзара салым кертү һәм аны җирле әһәмияткә ия түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә куллануга ризамы:

**Торак пункт чикләрендәге җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзекләндерү:**

-Кзыл Тау торак пунктында урамнарны төзекләндерү (балчык белән күтәртү, вак таш сатып алу һәм җәю, торбалар сатып алу);

**“РИЗА” “КАРШЫ” “ТОТКАРЛАНУЧЫ”**

Җыен беркетмәсе нигезендә:
Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган 175 кеше теркәлгән, җыенда катнашып, тавыш биргән кешеләр саны-124.
Җыенда катнашучыларның кул күтәреп тавыш бирүләре нәтиҗәсендә тавышлар түбәндәгечә билгеләнде:

“Риза” дип 124 кеше тавыш биргән
“Каршы” дип 0 кеше тавыш биргән
“Тоткарланучы” 0 кеше.

1. Алда китерелгән мәгълуматлар нигезендә халык җыены

2. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кыязлы авыл җирлеге составына керүче Кзыл Тау торак пунктында үткәрелгән халык җыенын уздырылган дип, җыен нәтиҗәләрен -**дөрес** дип исәпләргә.
3. Җыенда күтәрелгән түбәндәге мәсьәлә буенча чыгарылган карарны кабул итәргә: “Сез 2021 нче елда Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кыязлы авыл җирлеге составына керүче Кзыл Тау авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, I төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм көндезге бүлектә белем алучы студентлардан тыш, 400 сум күләмендә үзара

салым кертергә һәм җелган акчаларны җирле әһәмияткә ия түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә куллануга ризамы:

**1.Торак пункт чикләрендәге җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзекләндерү:**

-Кзыл Тау торак пунктында урамнарны төзекләндерү (балчык белән күтәртү, вак таш сатып алу һәм җәю, торбалар сатып алу) **кабул ителгән дип санарга.**

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә. Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында: http://aksubayevo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга

3. Карарны Татарстан Республикасының норматив хокукый актлар регистрына кертү өчен җибәрергә.

Иске Кызлы авыл җирлеге башлыгы: Г.Г.Дәүләтшин

СОВЕТ СТАРОКИЗЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ